КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1004

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 3 август, 400 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы белем алучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 3 август, 400 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 ноябрь, 669 нчы; 2016 ел, 30 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 23 гыйнвар, 29 нчы; 2018 ел, 29 март, 192 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белем алучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәгә, 6 нчы пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«D» категориядәге транспорт чарасын йөртүче сыйфатында эш стажы соңгы ел һәм бер ай эчендә балалар төркемнәрен оештырылган рәвештә йөртә башлаган көнгә кимендә бер ел булган;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин